Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № VI-6**

Балык Бистәсе штп. 2015 елның 19 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Башкарма комитетының Анатыш авыл җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән Анатыш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булган сурәттә җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлеге турында Килешүне раслау хакында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 421 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 8 маддәсендәге 4 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Башкарма комитетының Анатыш авыл җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән Анатыш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булган сурәттә җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлеге турында Килешүне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2015 елның 19 декабрендәге
VI-6 номерлы карарына кушымта

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның ___ _________ _____ номерлы карары белән расланды | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Советының 2015 елның ___ _________ _____ номерлы карары белән расланды |

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Башкарма комитетының Анатыш авыл җирлеге территориясендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән, Анатыш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булган сурәттә, җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлеге турында Килешү**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы, алга таба Палата дип аталучы, Рәисе йөзендә, Нигезләмә нигезендә эш итүче, бер яктан һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Башкарма комитеты, алга таба “җирлек Башкарма комитеты” дип аталучы, авыл җирлеге Башлыгы йөзендә, Устав нигезендә эш итүче, икенче яктан, Россия Федерациясе Граждан кодексының 421 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 8 маддәсендәге 4 өлеше нигезендә түбәндәгеләр хакында әлеге Килешүне төзеделәр.

## 1. Килешү предметы һәм принциплары

1.1. Әлеге Килешү Палата һәм Башкарма комитетның Анатыш авыл җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән Анатыш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булган сурәттә җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлеге тәтибен тәгаенли (алга таба – җир кишәрлекләре).

1.2. Әлеге Килешү түбәндәге принципларга нигезләнгән:

а) җирлек халкының мәнфәгатьләрен тәэмин итү, халыкка җирле үзидарәгә хокукны гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү;

б) җирлек территориясендә җирле үзидарәне нәтиҗәле үстерүгә ярдәм итү;

в) җирле үзидарәне торгызу һәм үстерү өчен кирәкле хокукый, оештыру шартлары тудыру;

г) җирлекнең башкарма комитеты җир кишәрлекләре белән эш итү буенча карарлар кабул итү буенча үзенә караган вәкаләтләрне мөстәкыйль гамәлгә ашыру;

д) җир сәясәте бердәмлеге;

е) гамәлдәге законнар нормаларын исәпкә алып, документларны сыйфатлы рәсмиләштерү.

## 2. Якларның бурычлары

2.1. Палатаның бурычлары:

2.1.1. җирлекнең Башкарма комитетына җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләрендә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән гамәлләрне башкару, шул исәптән:

а) физик һәм юридик затлардан документларны кабул итүне оештыру;

б) җир кишәрлекләрен муниципаль район органнары һәм учреждениеләре, шулай ук дәүләт хакимияте органнары белән эш итү мәсьәләләре буенча җирлек Башкарма комитетының әзерләнә торган карар проектларын һәм документларын килештерү кирәк булган очракта оештыру;

в) җир кишәрлекләре белән эш итү мәсьәләләре буенча җирлек Башкарма комитетының карар проектларын әзерләүдә ярдәм итү, шул исәптән: җир кишәрлеген (законда билгеләнгән очракларда) алдан килештерү турында, милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирүне, җир кишәрлекләреннән сервитут билгеләмичә генә файдалануга рөхсәтнамә бирүне, түләүсез файдалануны һәм җирләрдән файдалану буенча теләсә кайсы төр (сервитутлар) яисә башка чикләүләр билгеләү турында;

г) аренда шартнамәләре проектларын әзерләүдә, сату-алуда, түләүсез файдалануда, чикләнгән файдалануда (сервитут) ярдәм күрсәтү;

д) җир кишәрлеген алмаштырганда карарлар (шулай ук алмашу шартнамәсе проекты) әзерләүдә ярдәм күрсәтү;

е) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалык проектларын әзерләүдә ярдәм күрсәтү, җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турындагы карарлар һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турындагы килешү төзүдән баш тарту;

ж) законнарда билгеләнгән очракларда җир кишәрлеген урнаштыру схемасын, шулай ук җирле үзидарә органының аны раслау буенча карары проектын әзерләүдә ярдәм күрсәтү;

з) җирлек башкарма комитетының җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турындагы (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) карарлары проектларын әзерләүдә ярдәм күрсәтү, җир кишәрлегеннән

рөхсәт ителгән файдалану төрен билгеләү, җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турында;

и) җир кишәрлекләрен сату буенча карарлар, башка документлар проектларын әзерләүдә һәм торгларны оештыруда ярдәм күрсәтү, шулай ук аренда шартнамәләрен һәм җир кишәрлекләренә карата хокукларның күчүен күздә тоткан башка шартнамәләрне төзү хокукына торглар;

к) төзелгән шартнамәләр чикләрендә җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләүләрне тикшереп торуны гамәлгә ашыру һәм бурыч түләү турында дәгъвалар әзерләүдә ярдәм күрсәтү;

л) җир кишәрлекләре белән эш итүгә бәйле салым булмаган керемнәрнең аерым төрләренең керүен тулысынча һәм үз вакытында исәпкә алуны һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыру, әлеге керемнәрне администрацияләү һәм федераль казначылык идарәсенең Татарстан Республикасы буенча территориаль бүлекләре белән үзара хезмәттәшлекне оештыру;

м) федераль статистик күзәтү рәвешләре буенча хисаплылыкның дәүләт статистикасы органнарына тапшырылуын тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү;

н) әлеге Килешүдә билгеләнгән мәсьәләләр буенча җирлек башкарма комитеты мәнфәгатьләрен оешмалар, кредиторлар, гомуми юрисдикция судлары, арбитраж судларда ышанычнамә нигезендә тәкъдим итү;

о) әлеге Килешүдә билгеләнгән мәсьәләләр буенча дәүләт хакимияте органнары һәм муниципаль берәмлекләр арасында үзара хезмәттәшлекне оештыру;

п) дәүләт теркәве органнарында җир кишәрлекләренә һәм алыш-бирешләргә хокукның һәм милек хокукының күчү ышанычнамәсе нигезендә теркәлү;

р) тиешле кадастр эшләрен үтәгән очракта җир кишәрлеге чикләре урынын килештерү буенча бәяләмәләр әзерләүдә ярдәм күрсәтү, нәтиҗәдә җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны төгәлләштерелә;

с) җиргә дәүләт милке чикләнгәндә авыл җирлекләре хокукларын дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү;

2.1.2. Әлеге Килешүнең 2.1.1 пунктында күрсәтелгән гамәлләрне башкарганда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәүне тәэмин итү;

2.1.3. җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча җир кишәрлекләренә карата кирәкле мәгълүмат бирү;

2.1.4. җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча җирлек Башкарма комитетына консультатив-хокукый ярдәм күрсәтү;

2.2. Җирлек Башкарма комитетының бурычлары:

2.2.1. җирлек Башкарма комитеты карарлары проектларын, шартнамәләр һәм килешүләр проектларын әзерләү өчен кирәкле документларны Палата гарызнамәсе буенча тапшыру;

2.2.2. Палатага, җирлек Башкарма комитеты исеменнән гамәлләр башкаруга әлеге Килешү вәкаләтләре чикләрендә ышанычнамә тапшырылган очракта;

2.2.3. Палатага булган җир-кадастр, җир төзелеше һәм шәһәр төзелеше документларын, башка документларны бирү һәм Палата тарафыннан җир кишәрлекләре белән идарә итү документлары проектларын әзерләүдә ярдәм итүгә юнәлдерелгән гамәлләр башкару өчен кирәкле булган мәгълүматны бирү;

2.2.4. мәгълүмати-белешмә хезмәт күрсәтүне тәэмин итү;

2.2.5. җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча әзерләнгән карар проектларын үз вакытында имзалау һәм теркәү.

## 3. Килешүнең гамәлдә булу вакыты һәм аны туктату тәртибе

3.1. Әлеге Килешү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Анатыш авыл җирлеге Советы раслаган көннән үз көченә керә һәм өч ел дәвамында гамәлдә була.

3.2. Әлеге Килешү якларның килешүе буенча вакытыннан алда туктатыла.

3.3. Килешүне өзү язма рәвештә рәсмиләштерелә.

3.4. Бу Килешүне вакытыннан алда туктату турында карар кабул иткән як икенче якка өзү көненә 30 көн кала хәбәрнамә һәм өзү турында Килешү проектын җибәрә. Өзү турында хәбәрнамәне һәм килешү проектын алган як кул куелган өзү килешүен яисә кире кагуны 10 көн эчендә җибәрергә тиеш.

3.5. Әлеге Килешүнең гамәлдә булу срогы тәмамланырга бер ай кала якларның берсе дә аны өзүне таләп итмәсә, Килешү шул ук срокка һәм шул ук шартларда озайтылган дип санала.

## 4. Якларның җаваплылыгы

4.1. Яклар гамәлдәге законнар нигезендә бу Килешүдә каралган бурычларны үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү өчен җаваплы.

## 5. Йомгаклау шартлары

5.1. Якларның үзара ризалыгы буенча яки гамәлдәге закон таләпләре нигезендә әлеге Килешүгә язма рәвештә үзгәрешләр һәм (яки) өстәмәләр кертелергә мөмкин.

Әлеге Килешүгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр якларның өстәмә килешүе белән рәсмиләштерелә.

5.2. Әлеге Килешү якларның һәрберсе өчен тигез юридик көчкә ия 2 (ике) нөсхәдә төзелгән.

5.3. Бу Килешүне үтәгәндә яклар арасында килеп чыккан барлык бәхәсләр һәм каршылыклар сөйләшүләр аша хәл ителәчәк.

5.4. Әлеге килешүдә җайга салынмаган мәсьәләләр, шул исәптән финанс тәэминатын да, муниципаль берәмлекләрнең аерым актлары, гамәлдәге законнар нигезендә кабул ителгән килешүләр белән җайга салына.

## 6. Якларның адреслары һәм башка мәгълүматлар

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы
422650, ТР, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин ур., 48а йорт

Рәис
______________________________

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Башкарма комитеты

422650, ТР, Балык Бистәсе муниципаль районы, Анатыш ав., Клуб ур., 19 йорт

Авыл җирлеге Башлыгы
_____________________ К.К.Җамалиев